РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» апрель 2023 ел г. Альметьевск № 1020

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 2022 елның 18 октябрендәге 2393 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасында региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 сентябрендәге 699 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 24 мартындагы 331 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 2022 елның 18 октябрендәге 2393 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

искәрмәдәнең икенче абзацындагы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан региональ яисә муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» 2022 елның 07 мартындагы 199 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә 2022 елда кертелә торган хәрәкәтне вакытлыча чикләү кертү чорында» сүзләрен «Татарстан Республикасы региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү гамәлдә булган чорда» сүзләре белән алыштырырга.

Зак. № 305-2000

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Настоящее постановление вступает в силу после его официального опубликования.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Р.06-12061/12 ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ ИНН 1644035822 КПП 164401001 ОГРН 1051605067172